**Дүртенче чакырылыш**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре                № 97-12                «14» декабре 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Азнакай муниципаль районы Уставы нигезендә, Азнакай муниципаль районының «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын тикшерү буенча 2021 елның 30 ноябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис                                                  М. З. Шәйдуллин